**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

______________ ______________

Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 19.11.2013 № 670-п приказы белән расланган, авыл хуҗалыгы өчен яраклаштырылган җирләрне башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 19.11.2013 № 670-п приказы белән расланган (Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министрлыгының 21.02.2014 № 113-п приказы тарафыннан кертелгән үзгәрешләр белән), авыл хуҗалыгы өчен яраклаштырылган җирләрне башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта:

1.3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан ш., Павлюхин ур., 75 йорт.

Дәүләт хезмзтен күрсәтү буенча Министрлыкка документлар һәм мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен почта адресы: 420049, Татарстан Республикасы, Казан ш., Павлюхин ур., 75 йорт.

Министрлыкның эшләү вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 – 18.00, җомга 9.00 – 16.45, төшке аш вакыты 12.00 – 12.45.

Җәмәгать транспортында “Павлюхин урамы” тукталышына кадәр түбәндәге маршрутларда барып була:

автобуслар: №№ 2, 4, 5, 25, 31, 37, 43, 47, 69, 69а, 74, 74а, 77;

троллейбуслар: №№ 6, 8, 12.

Министрлыкка керү шәхесне раслаучы документ буенча башкарыла.

1.3.3 пунктчада “Кушмтада (белешмәдә)” сүзләрен “№4 кушымтада сүзләренә үзгәртергә;

1.3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3.4. Мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендәге Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати “Татарстан Республикасының рәсми порталы” системасына кергән Министрлыкның рәсми сайтының адресы (алга таба – Министрлыйның рәсми сайты һәм “Интернет” челтәре): http://eco.tatarstan.ru, электрон почта адресы: eco@tatar.ru.»;

Административ регламентның 1.3.6 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Мәгълүмати такталарда урныштырылган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында булган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында хәбәрләрне үз эченә ала.”;

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.4. Дәүләт вазифасын күрсәтү тормышка ашырыла:

25.10.2001 №136-ФЗ Россия Федерациясенең җир кодексы (алга таба – РФ җир кодексы), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2001, № 44, 4147 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

29.12.2004 №190-ФЗ Россия Федерациясенең шәһәр төзелеш кодексы (алга таба – РФ шәһәр төзелеш кодексы), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2005, № 1 (1нче бүлек), 16 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

03.06.2006 № 74-ФЗ Россия Федерациясенең су кодексы (алга таба – РФ су кодексы), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2006, № 23, 2381 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

04.12.2006 №200-ФЗ Россия Федерациясенең урман кодексы (алга таба – РФ урман кодексы), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2006, № 50, 5278 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

21.02.1992 №2395-1“Җир асты турында” Россия Федерациясенең законы (алга таба – РФ Законы №2395-1), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1995, №10, 823 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

03.02.1995 №26-ФЗ “Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар турында” Федераль закон (алга таба – №26-ФЗ Федераль закон), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1995, №9, 713 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

14.03.1995 №33-ФЗ “Аеруча саклანучы табигый территорияләр турында” Федераль закон (алга таба – №33-ФЗ Федераль закон), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1995, №12, 1024 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

24.04.1995 №52-ФЗ «Хайваннар дөньясы турында” Федераль закон (алга таба - №52-ФЗ Федераль закон), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1995, №17, 1462 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

21.11.1995 №170-ФЗ «Атом энергиясен куллану турында» Федераль закон (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1995, №48, 4552 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

23.11.1995 №174-ФЗ «Экологик экспертиза турында» Федераль закон (алга таба – №174-ФЗ Федераль закон), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1995, №48, 4556 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

09.01.1996 №3-ФЗ «Халыкның радиацион иминлеге турында» Федераль закон (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1996, №3, 141 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында” 30.03.1999, № 52-ФЗ Федераль законы (алга таба – Федераль закон №52-ФЗ) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Әйләнә-тирә мөхитне саклау турында» 10.01.2002, №7-ФЗ Федераль законы (алга таба – Федераль закон №7-ФЗ) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җирне яисә җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында” 21.12.2004 №172-ФЗ Федераль закон (алга таба – №172-ФЗ Федераль закон), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2004, № 52 (1 бүлек), 5276 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында” 24.07.2007 №221-ФЗ Федераль закон (алга таба – №221-ФЗ Федераль закон), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2007, № 31, 4017 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010, № 210-ФЗ Федераль законы (алга таба – Федераль закон №210-ФЗ) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җитештерү процессларын тормышка ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрен, элемтә һәм электр юлларын эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының үлемен кичектерү өчен таләпләр турында” 13.08.1996 №997 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – №997 РФ Хөкүмәте карары), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1996, № 37, 4290 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Атом-төш кулланмалар, радиацион чыганаклар һәм саклау пунктларын төзү һәм урнаштыру турында кагыйдәләр турында” 14.03.1997 №306 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1997, № 12, 1442 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Файдалы казылмалар булган урыннарны табу өчен техник проектларны һәм башка файдалы казылмалар белән бәйле җир кишәрлекләрен куллану өчен проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау хакында нигезләмәне раслау турында” 03.03.2010 №118 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – №118 РФ Хөкүмәте карары), (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2010, № 10, 1100 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт функцияләрен башкару турында административ регламентларны һәм Дәүләт вазифаларын күрсәтү турында административ регламентларны эшләү һәм раслау турында” 16.05.2011 №373 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2011, № 22, 3169 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” 2.07.1-89 төзү нормалары һәм кагыйдаләре (алга таба – СНиП 2.07.01-89), (20.05.2011 соң “Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү” СП 42.13330.2011 кулланылышка кертелә. 28.12.2010 №820 Россия Федерациясенең региональ үсеш Министрлыгының приказы белән расланган, СНиП 2.07.01-89 актуаль редакциясе);

“Су асты суларын саклауга гигиеник таләпләр” 2.1.5.1059-01 санитар кагыйдәләр (алга таба - СП 2.1.5.1059-01), (башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив актларының бюллетене, 2001, №38);

“Су белән тәэмин ителеш һәм эчәр өчен яраклы су чыганакларын санитар саклау” 2.1.4.1110-02 санитар кагыйдәләр һәм нормалар (алга таба – СанПиН 2.1.4.1110-02), (Башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив актлар бюллетене, 2002, №19);

радиоактив калдыклар белән эш итү санитар кагыйдәләре (СПОРО 2002) СП 2.6.6.1168-02 (алга таба – СП 2.6.6.1168-02), (Башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив актларының бюллетене, 2003, №3, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Радиацион куркынычсызлыкны тәэмин итүнең төп санитар кагыйдәләрен (ОСПОРБ 99/2010)” раслау турында” 26.04.2010 №40 РФ Төп дәүләт санитар врачы карары белән расланган радиацион куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча санитар кагыйдәләр (алга таба – СП 2.6.1.2612-10), (Россия газетасы, 2010, 17 сентябрь (махсус чыгарылыш), кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Табигатне саклау. Гидросфера. Җир асты суларын саклауга гомуми таләпләр” дәүләтара ГОСТ 17.1.3.0682 стандарты (алга таба – ГОСТ 17.1.3.06.82), (25.03.1982, № 1244 СССР Дәүләт стандарты карары белән кулланылышка кертелгән);

“Табигатне саклау. Җирләр. Җирләрне рекультивацияләүгә гомуми кталәпләр” дәүләтара ГОСТ 17.5.3.4-83 стандарты (алга таба – ГОСТ 17.5.3.04-83), (30.03.1983, № 1521 СССР Дәүләт стандарты карары белән кулланылышка кертелгән);

“Табигатне саклау. Җирләр. Җир эшләрен башкарганда җирнең уңдырышлы катламын саклауга карата таләпләр” дәүләтара ГОСТ 17.4.3.02-85 стандарты (алга таба – ГОСТ 17.4.3.02-85), (05.05.1985, № 1521 СССР Дәүләт стандарты карары белән кулланылышка кертелгән, ГОСТ текстсы Россия Дәүләт стандартының рәсми басмасы буенча китерелә, ИПК Стандартлар нәшрияте, 2004 ел);

“Авто ягулык станцияләрен эксплуатацияләүнең техник кагыйдәләре” РД 153-39.2-080-01 җитәкчелек документы (алга таба – РД 153-39.2-080-01),(РФ Минэнерго 01.08.2001 №229 приказы тарафыннан кулланылышка кертелгән, документ текств “Техносматива” басмасы буенча китерелә (Мәскәү, 2012 ел), кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасының Җир кодексы (алга таба РТ Җир кодексы) (Татарстан Дәүләт Советы Хәбәрләре, 1998, №8 (II бүлек),, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасының Экологик кодексы (Татарстан Дәүләт Советы 25.12.1992 №1722-XII «Җирләр турында” Татарстан Республикасы законы (алга таба – №1722-XI РТ Законы), (Татарстан Республикасының Югары Советы Хәбәрләре, 1992, №11-12, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республшикасының экология һәм табигый ресурслар министрлыгының сораулары” 06.07.2005 №325 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алага таба – карар КМ РТ № 325 ) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2005, №28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының Татарстан Республикасы вәкаләтләрен дәүләт унитар оешмалары исемлеген раслау турында һәм Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 25.08.2005 №416 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2005, № 33-34,0778 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Авыл хуҗалыгы өчен каралган җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү өчен гариза бирү формасын һәм гариза белән бергә тапшырылучы документлар исемлеген раслау турында” 25.10.2006 №523 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 523 ТР МК карары), (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2006, № 41-42,1061 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы Министрлыгы сораулары” Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты 12.02.2007 № 38 карары тарафыннан расланган, Татарстан Республикасын Урман хуҗалыгы Министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – ТР Урман хуҗалыгы Министрлыгы турында нигезләмә), (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2007, №8, 0330 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы министрлыгы сораулары” 18.04.2008 №246 Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары тарафыннан расланган, Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм куллану Идарәсе турында нигезләмә (алаг таба – ТР хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм куллану Идарәсе турында нигезләмә), (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2008, № 19, 0702 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен хезмәтен күрсәтү турында административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 №880 Татарстан

Республикасының Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасының башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен  хезмәтен күрсәтү турында административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Тәртип) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2005, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Җир астыннан файдалы казылмаларын табу һәм эзләү белән шөгыльләнүче яки геологик тикшеренүгә лицензиясе булган җир асты җирләрен кулланучылар тарафыннан үзләренең җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен аларга бирелгән “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тау тармакларында һәм (яки) геологик тармакларда киң җәелгән файдалы казылмаларны табу тәртибен раслау турында” 21.12.2011 № 1042 Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары (алга таба – ТР МК № 1042 карары), (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2012, № 4, 0120 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы территориясендә киң җәелгән файдалы казылмаларны табу, җир асты кулланмаларын һәм көнкүреш коеларны, скваҗиналарны җир кишәрлекләренең милекчеләре, җир кулланучылары, җирияләре һәм җир кишәрлекләрнең арендаторлары тарафыннан казу һәм төзү тәртибен раслау турында” 29.02.2012 №171 Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары (алга таба – ТР МК № 171 карары), (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2012, №26, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының ягулык комплексы объектларында экологик куркынычсызлыкны һәм ресурсларны саклауга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру турында” 06.02.2013 № 152-р Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты  күрсәтмәсе (алга таба – ТР МК күрсәтмәсе № 152-р), (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр җыентыгы һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары” журналы, 2013, №14, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).”;

түбәндәге эчтәлекле 1.5 пункт белән тулыландырырга:

“1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм атамалар кулланыла:

**дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза** (алга таба – гариза) – № 210-ФЗ Федераль законның 1 пункты 2 статьясы тарафыннан каралган гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәтүне соравы. Гариза ирекле формада әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны кертеп төзелә;

**техник хата** – Министерство тарафыннан ясалган һәм бирелгән документларга кертелгән хәбәрләрнең документлардагы мәгълүматлар белән туры килмәвенә китергән хата (ялгышлык,  төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар);

**дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче куп функцияле үзәкнең читтәге эш урыны** – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә урнашкан, гариза бирүчеләрне канссультацияләү, документларны кабул итү һәм бирү урыны (алга таба – читтән торып эшләү урыны);

2 бүлектә:

“Стандартка таләпнең атамасы” графасының атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына таләпнең атамасы”;

“Стандартка таләпнең эчтәлеге” графасының атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Стандартка таләпләрнең эчтәлеге”;

2.1 пунктта “Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“РФ җир кодексының 10, 39.1, 39.9, 39.15, 78 ст.; №7-ФЗ Федераль законның 6, 34 ст.; №172-ФЗ Федераль законның 2,7 ст.; Нигезләмәнең 3.3 п. 3.3.9 пунктчасы; №523 КМ РТ карары”;

2.2 пунктта “Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Нигезләмәнең 3.3 пунктының 3.3.9 пунктчасы”;

2.3 пунктта “Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“РФ Җир кодексының ст. 12, п. 1 ст. 13, ст. 39.1, ст. 39.9, ст. 39.15, ст. 40, ст. 42, п. 2 ст. 56, п.п. 9, 10 ст. 85, ст. 88, п.п. 2, 6 ст. 94, п. 3 ст. 96; РФ Су кодексының ст. 6, ст. 42, ч. 2 ст. 43, ч. 2 ст. 50, ч. 2 ст. 52, ч.ч. 1, 4, 5 ст. 59, ч. 5 ст. 60, ст. 64, ст. 65; РФ Урман кодексының ч. 4 ст. 12, ч.ч. 2, 5 ст. 102; №7-ФЗ Федераль законның ст. 32 - 34, п.п. 2, 3 ст. 44, п. 1 ст. 48, ст. 51, п. 2 ст. 61; №52-ФЗ Федераль законның ст. ст. 12, 22; №3-ФЗ Федераль законның ст. 6; №172-ФЗ Федераль законның ст. 7-12; №174-ФЗ Федераль законның ст. 11, 12; №221-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 14ч., п.п.12; №2395-1 Федераль законның п.п. 8, 11 ч. 1 ст. 23; №26-ФЗ Федераль законның п. 3 ст. 16; № 1722-XII РТ Законының 24 ст; № 997 РФ Хөкүмәтенең карары; № 118 РФ Хөкүмәтенең карары; ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3 п. 3.3.3 пунктчасы; ТР хайваннар дөньясының объектларын саклау һәм кулlануны көйләү турындагы Нигезләмәнең 4.1 рункты; № 152-р ТР МК карары; СП 2.1.5.1059-01; СП 2.6.6.1168-02; СП 2.6.1.2612-10; ГОСТ 17.1.3.06-82; ГОСТ 17.5.3.04-83; ГОСТ 17.4.3.02-85; раздел 4 СНиП 2.07.01-89; п. 18.2 РД 153-39.2-080-01»;

2.4 пунктта;

“Стандартка таләпнең атамасы” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.4. Дәүләт хезмәтенең күрсәтелү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү вакытын, Россия Федерациясе законнар җыентыгы тарафыннан карлган булса, дәүләт хезмәте срогын туктатуны исәпкә алып”;

“Стандартка таләпнең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның авыл хуҗалыгы өчен яраклаштырылган җирләрне башка категориягә күчерүне килештерү буенча бәяләмәсе – гариза кабул итеп алынганнан соң җиде көн дәвамында. Министрлыкның авыл хуҗалыгы өчен яраклаштырылган җирләрне башка категориягә күчерүне килештермәү турында бәяләмәсе – гариза кабул итеп алынганнан соң җиде көн дәвамында”;

түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган”;

2.5 пунктта:

“Стандартка таләп атамасы” графасын “, гариза бирүченең алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү ысуллары” сүзләре белән тулыландырырга;

“Стандартка таләп эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Авыл хуҗалыгы өчен яраклаштырылган җирләрне башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәтен алу өчен гаризага беркетелә:

1. Гаиза бирүченең шәхесен ачыклаучы документлар.

2. Ышанычнамә (гариза вәкаләтле вәкил тарафыннан имзаланса).

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм беркетелгән документлар гаиза бирүче тарафыннан кәгазьдә киләсе ысулларның берсе белән тапшырыла (җибәрелә ала):

шәхсән (ышанычнамә нигезедә, гариза бирүче исеменнән эш итүче йөз тарафыннан);

почта аша махсус заказлы хат белән (хатны кабул итеп алу турындагы кисәтү белән).

Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан электрон документ рәвешендә, көчәйтелгән квалификацион имза белән имзаланган, информацион һәм коммуникацион челтәрләр аша, шул исәптән, информацион һәм коммуникацион “Интернет” челтәре аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең Бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин”;

“Дәүләт хезмәтен яки таләбен билгеләүче норматив акт” графасын түбәдәге редакциядә бәян итәргә:

“РФ Җир кодексының 39.1, 39.9, 39.15 ст., ТР МК №523 карары”;

2.6. пунктта:

“Стандартка таләп атамасы” графасын “, шулай ук аларны гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы, яисә карамагына әлеге документлар булган оешма” сүзләре белән тулыландырыга;

“Стандартка таләпнең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәәргә:

“Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында китерелгән.

Өстә күрсәтелгән документлар дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә башка оешмалар карамагында булган очракта, аларны гариза бирүчедән таләп итү тыела”;

“Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт” графасында 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“РФ Җир кодексының п.п. 4, 5 ст. 27, п. 2 ст. 56, п. 4 ст. 79, п.п. 9, 10, 12 ст. 85, п. 2 ст. 88, п.п. 2, 3, 6 ст. 90, п.п. 2, 6 ст. 94, п.п. 3, 5, 7 ст. 95, п. 3 ст. 96, п. 3, 4 ст. 97, п. 5 ст. 98, п. 1 ст. 100, п. 2 ст. 102; РФ Су кодексының ст. ст. 6, 65; РФ Урман кодексының ст. 12, ч.ч. 2, 5 ст. 102; №7-ФЗ Федераль законның ст. 3, п. 4. ст. 58, п. 2 ст. 59, п. 1 ст. 60, п. 2 ст. 61, ст. 62; №33-ФЗ Федераль законның п. 1 ст. 9, п. 4 ст. 21, п. 1 ст. 24, п. 1 ст. 27, п. 1 ст. 29; №26-ФЗ Федераль законның п. 3 ст. 16; РФ №2395-1 Законның 8 ст.; СП 2.1.5.1059-01; СП 2.6.6.1168-02; СП 2.6.1.2612-10»;

“Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт” графасында 2.10 пунктта “ТР МК №845-р карары” сүзләрен төшереп калдырырга;

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасында 2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Кирәкле һәм махсус хезмәт күрсәтүләр кирәкми”;

“Станартка таләпләр эчтәлеге” графасында 2.12 пунктны “Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират каралмаган” сүзләре белән тулыландырырга”;

2.13 пунктта:

“Стандартка таләп атамасы” графасын “... шул исәптән, электрон формада” сүзләре белән тулыландырыга;

“Стандартка таләпнең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гариза кабул итеп алынган көнне”;

2.14 пунктта:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандары таләбенең атамасы” графасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

“2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелүче биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урыннарына, инвалидлар өчен Россия Федерациясенең инфалидларны социаль яклау законччылыгы буенча каршылыксыз керүгә, визуаль, текст һәм мультимедия форматылардагы дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы мәгълүмат урнаштыруга таләпләр”;

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү һава чистарту җайланмалары, янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар һәм мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәтен күрсәтү урыннарына каршылыксыз керү мөмкинлеге тудырыла (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә уңайлы хәрәкәт итү).

Визуаль, текст һәм мультимедия форматылардагы дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен дә исәпкә алып.

“Гаризаны Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталы аша биргән очракта гариза бирүче гаризаны районнарның башкарма комитетларында һәм шәһәр округларында тапшыра ала (№4 кушымта)”;

2.15 пунктта:

“Стандартка таләп атамаы” графасын “, “шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәтен алганда вазыйфаи затлар белән аралашу саны һәм аларның дәвамы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең читтән торып эш урыннары, дәүләт хезмәтен алу барышында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, информацион һәм коммуникацион технологияләрне кулланып” сүзләре белән тулыландырырга;

“Гаризага таләп атамасы” графасын “шул исәптән, ... сүзләре белән тулыландырырга

“Стандартка таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең ачыклыгын түбәндәге күрсәткечләр дәлилли:

кабул итү урыннарының җәмәгать транспорты тукталышына якын урыннарда урнашуы;

гариза бирүчеләрдән документларны алу өчен җитәрлек кабул итү урыннары һәм белгечләрнең булуы;

информацион стендларда, ресурсларда, “Интернет” челтәрендә, Министрлыкның официаль сайтында дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирә алу мөмкинлеге;

гариза бирүченең дәүләт хезмәтенең нәтиҗәләрен электрон формада Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү Порталында шәхси кабинетында алу мөмкинлеге, документларын Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү Порталы аша биргән очракта (гаризаны һәм документларны Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү Порталы аша бирү мөмкинлеге бөлдырылганнан соң);

инвалидларга хезмәт күрсәтүне алуга комачаулык итүче каршылыкларны башкалар белән бертөсле үтергә ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре:

документларны кабул итү һәм карау срокларын вакытында үтәү;

дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алу срокларын вакытында үтәү;

дәүләт хезмәткәрләренең әлеге Регламентны бозуы хакында нигезләнгән шикаятьләрнең булуы,

гариза бирүченең белгечләр белән эшләү күләме:

дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм дәүләт хезмәтен алу өчен гариза тапшырган вакытта – икендән дә күп түгел (консультацияләрне санамаганда);

дәүләт хезмәтен алу өчен гариза һәм документларны почта аша җибәргәндә - юк (консультацияләрне санамаганда);

документларны Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү Порталыннан шәхси кабинет аша җибәргән очракта:

1. № 63-ФЗ Федераль закон № 210-ФЗ Федераль закон буенча гариза һәм документларның копияләре электрон имза белән электрон рәвештә җибәрелсә – аларашу каралмаган;

2. № 63-ФЗ Федераль закон № 210-ФЗ Федераль закон буенча гариза һәм документларның копияләре электрон имзасыз белән электрон рәвештә җибәрелсә – аларашу бер тапкырдан да күбрәк түгел.

Бер гариза бирүче белән аралашу 15 минуттан да озаграк була алмый.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бирү күпфункөияле үзәк, күпфункөияле үзәкнең читтән торып эшли трган эш урыннары аша бирелә алмый.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтен күрәтүнең тәртибе турында мәгълүматны http://www. eco.tatarstan.ru сайтыннан һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең Бердәм порталыннан ала ала.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул ук исәптән, дәүләт хезмәтен алуга гариза бирүне исәпкә алып, күпфункцияле үзәк, читтән торып эшләү урынары аша башкарылмый";

«Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт" графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

"Тәртипнең 2.4 пунктының "п" пунктчасы";

3 бүлектә:

бүлекнең атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Административ процедураларның составы, тәртибе һәм барышы, аларны башкарү тәртибе, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару тәртибе, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү буенча куп функцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында башкару тәртибе";

3.1 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) гариза бирүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү вакытында;

түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча белән тулыландырырга:

"6) техник хатаны төзәтү.";

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3.2. Гариза бирүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны нормалаштыру бүлегенә шәхсән, почта аша, телефон аша, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү Порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең Бердәм порталы аша һәм әлектрон почта аша дәүләт хезмәтен алу буенча консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлекнең белгече шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яки) хат белән, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниөипаль хезмәт күрсәтү Порталы аша, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулыннан чыгып, гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның формасы һәм эчтәлеге буенча да, һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән рәсмиләштергәндә дә.

Әлеге пункттагы процедура гариза биргән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның формасы һәм дәүләт хезмәтен алу буенча башка сораулар буенча консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.";

3.3.1 пунктта:

беренче абзацта “№1 кушымта нигезендә” сүзләрен төшереп калдырыга;

икенча абзацны “Җир кишәрлеген бирү шартлары №2 кушымтада күрсәтелгән.” сүзләре белән тулыландырырга;

3.3.3 пунктта:

бишенче абзацта “җир кишәрлеген сайлау актын куярга” сүзләрен төшереп калдырыга;

унбишенче абзацта “бер көн» сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.3.4 пунктта:

икенче абзацта “җир кишәрлеген сайлау акты белән бергә” сүзләрен төшереп калдырыга;

бишенче абзацта “өч көн» сүзләрен “өч эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

3.3.5 пунктта:

өченче абзацта “җир кишәрлеген сайлау акты һәм” сүзләрен төшереп калдырыга;

бишенче абзацта “бер көн» сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

икенче абзацта 3.3.12 пунктта “бер көн» сүзләрен “бер эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.4 һәм 3.5 пунктлар белән тулыландырырга:

3.4. “Техник хаталарны төзәтү (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар)

3.4.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хаталарны күргән очракта (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар), гариза бирүче Бүлеккә түбәндәге документларны тапшыра:

Техник хатаны (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) түзәтү турында гариза;

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган һәм хата (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар), булган документ;

Юридик көчкә ия булган һәм техник хата (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) булуныраслаган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хатаны (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) төзәтү турындагы гариза гариза бирүче тарафыннан (вәкаләтле вәкиле) шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә дәүләт һәм муниөипалҗ хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы аша тапшырыла.

3.4.2. Документларны кабул итеп алу өчен җаваплы белгеч дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хатаны (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) төзәтү турындагы гаризаны башка документлар белән берлектә кабул итеп ала һәм гаризны электрон рәвештә Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында терки.

Әлеге пунктчадангы проөедура гаризаны кабул итеп алган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул итеп алынган, теркәлгән һәм Бүлек белгеченә карауга җибәрелгән гариза.

3.4.3. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатыннан, Бүлек белгече документларны карый, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән, имзасын алып, тапшыра һәм гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хата (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) булган документның оригиналын үзенә алып кала, яки гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) Бүлеккә техник хата (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) булган документның оригиналны биргән очракта, документны алу мөмкинлеге хакында хат җибәрә.

Әлеге пунктчадагы профедура техник хатаны (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) күреп алганнан соң яисә кайсы булса да кызыксынган йөз тарафыннан техник хата турында (ялгышлык, төгәлсезлек, грамматик һәм арифметик хаталар) гариза алганнан соң 3 көн дәвамында башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

3.5. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк, читтән торып эшләү урыны аша күрсәтү тәртибе.

Дәүләт хезмәте (шул исәптән, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бирү) күпфункцияле үзәк, читтән торып эшләү урыны аша башкарылмый.”;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**“5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлыкның эшләренә, дәүләт хезмәтен күрсәтүне башкаручы Министрлыкның вазыйфаи йөзенә яки Министрлыкның дәүләт хезмәткәренә судка кадәр (судтан тыш) гариза бирүчедән шикаять язу.**

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар Министрлыкның эшләренә, Министрлыкның вазыйфаи йөзенә яки Министрлыкның дәүләт хезмәткәренә судка кадәр Министрлыкка шикаять язарга хокуклы. Министр тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кабул ителгән карарларга шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Гариза бирүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) гариза бирүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризасы теркәлү вакытының срогы чыккан очракта;

2) дәүтәт хезмәтен күрсәтүнең вакытын билгеләнгән сроктан артып китсә;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары тарафыннан каралмаган токументлар таләп ителсә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары тарафыннан билгеләнгән документларны гаиза бирүчедән кабул итмәгән очракта;

5) Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары тарафыннан баш тарту каралмаган булып та, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәтен алу өчен гариза тапшырганда гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары тарафыннан каралмаган түләү таләп итү;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы документтагы хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә төзәтүләрнең башкарылу вакыты билгеләнгән сроктан артып китсә.

5.2. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интеренет” челтәре аша, Министрлыкның рәсми сайты аша, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Бердәм порталы аша, шулай ук гариза бирүче тарафыннан шәхсән бирелә ала.

5.3. Дәүләт хезмәтен алучының шикаяте түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

Министрлыкның исеме, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме, шикаять бирүгә китергән эшләр;

Гариза бирүче - физик затның фамилиясе исеме, әтисенең исеме (булган очракта), тору урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) һәм почта адресы;

Министрлыкның шикаять бирүгә китергән эшләре хакында мәгълүмат, шулай ук аның вазыйфаи заты һәм дәүләт хезмәткәре турында;

гариза бирүченең Министррлыкның карары, яки вазыйфаи заты, яки дәүләт хезмәткәре белән риза булмавын раслаучы дәлилләр.

5.4. Министрлыкка килгән шикаять теркәлгәннән соң 15 көн дәвамында шикаятьләрне караучы вазыйфаи зат тарафыннан карала, әгәр дә Министрлыкның кире кагуына, Министрлыкның документлар кабул итүче вазыйфаи затына янадан шикаять бирелгән, хаталарны төзәткән очракта – 5 көн дәвамында.

Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар яисә аларның копияләре тапшырыла ала (булган очракта).

5.5. Шикаять гариза бирүче тарафыннан шәхсән яисә аның вәкаләтле вәкаләте тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәсендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган түбәндәге ике нәтиҗәнең берсенә килә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән нәтиҗәгә килгән карарны туктату формасында, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә Министрлык тарафыннан бирелгән документлардагы хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокууый актлары буенча һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары буенча тотып калынуы каралмаган акчаны кайтару, һәм башка фомаларда,

2) шикаятьне кәнәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән нәтиҗәгә килгән көннең икенче көненнән дә соңламыйча гариза җибәрүчегә хат яки электрон формада шикаятькә нигезләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау вакытында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре билгеләнгән очракта, шикаятьләрне караучы вазыйфаи зат булган материалларны шул ук вакытта прокуратура органнарына җибәрә.

Приложение № 1 изложить в следующей редакции:

№1 Кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Приложение № 1**
**к Административному регламенту**
**Министерства экологии и природных ресурсов**
**Республики Татарстан предоставления государственной**
**услуги по согласованию перевода земельного участка**
**из земель сельскохозяйственного назначения в другую категорию**

**“Татарстан Республикасының**
**экология һәм табигый байлыклар**
**министрлыгының авыл хуҗалыгы өчен яраклаштырылган җирләрне**
**башка категориягә күчерүне килештерү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең**
**Административ регламентына №1 Кушымта**

Министру экологии и природных ресурсов
Республики Татарстан

_______________________________________

От: __________________________________
(для индивидуальных предпринимателей:
Ф.И.О.,адрес (почтовый и (или) электронный)

_______________________________________
для юридических лиц: наименование
организации, адрес (почтовый
и (или) электронный)

**Заявление об исправлении технической ошибки**
**(описок, опечаток, грамматической или арифметической ошибки)**

Сообщаю об ошибке (описках, опечатках, грамматической или арифметической ошибке), допущенной при оказании государственной услуги

_____________________________________________________________________

(наименование услуги)

Записано: _______________________________________________________

_____________________________________________________________________

Правильные сведения: _____________________________________________

_____________________________________________________________________

Прошу исправить допущенную техническую ошибку (описки, опечатки, грамматическую или арифметическую ошибку) и внести соответствующие изменения в документ, являющийся результатом государственной услуги.

Прилагаю следующие документы:

1.

2.

3.

В случае принятия решения об отклонении заявления об исправлении технической ошибки (описок, опечаток, грамматической или арифметической ошибки) прошу направить такое решение:

посредством отправления электронного документа на адрес E-mail: ______________________;

в виде заверенной копии на бумажном носителе почтовым отправлением по адресу: ____________________________________________________________.

Подтверждаю свое согласие, а также согласие представляемого мною лица на обработку персональных данных (сбор, систематизацию, накопление, хранение, уточнение (обновление, изменение), использование, распространение (в том числе передачу), обезличивание, блокирование, уничтожение персональных данных, а также иных действий, необходимых для обработки персональных данных в рамках предоставления государственной услуги), в том числе в автоматизированном режиме, включая принятие решений на их основе органом, предоставляющим государственную услугу, в целях предоставления государственной услуги.

Настоящим подтверждаю: сведения, включенные в заявление, относящиеся к моей личности и представляемому мною лицу, а также внесенные мною ниже, достоверны. Документы (копии документов), приложенные к заявлению, соответствуют требованиям, установленным законодательством Российской Федерации, на момент представления заявления эти документы действительны и содержат достоверные сведения.

Даю свое согласие на участие в опросе по оценке качества предоставленной мне государственной услуги по телефону: _____________.

| | | |
|---|---|---|
| ___________________ | _____________ | (_____________________) |
| (дата) | (подпись) | (Ф.И.О.).»; |

№2 Кушымтада:

2 пунктта “(РФ Шәһәр төзелеш кодексы 49.1 ст) сүзләрен “(РФ Шәһәр төзелеш кодексы 49 ст.)” сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт белән тулыландырырга:

“2.1 Территориаль планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү буенча дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алу (№174-ФЗ Федераль законның 12 ст.)”;

3 пунктта:

“№2395-1 Федераль закон» сүзләрен “№2395-1 РФ Законы” сүзләре белән алмаштырырга”;

“№97 “Татарнедр” приказы” сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта “№2395-1 Федераль закон» сүзләрен “№2395-1 РФ Законы” сүзләре белән алмаштырырга;

14 пунктта:

“№2395-1 “Җир асты” РФ Законы” сүзләрен “№2395-1 РФ Законы” сүзләре белән алмаштырырга;

“№1722-XII “Җир асты” РТ Законы” сүзләрен “№1722-XII РФ Законы” сүзләре белән алмаштырырга;

15 пунктта:

“№ 2395-1 “Җир асты” РТ Законы” сүзләрен “№ 2395-1 РФ Законы” сүзләре белән алмаштырырга;

“№1722-XII “Җир асты” РТ Законы” сүзләрен “№1722-XII РФ Законы” сүзләре белән алмаштырырга;

№3 Кушымтада:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6. Алдан алынган җирләрне кабаттан торгызмау (РТ Җир кодексының ст. ст. 13, 39.8, 39.35, 45, 78)”.

№4 Кушымтада:

“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ бүлегенең “Үзәк территориаль идарә” графасында:

“Телефон” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«(8-843) 267-68-66; 267-68-33, 264-23-07 (кабул итү бүлеге)»;

“Адрес” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«420049, Казан ш., Павлюхин ур., 75, 4 эт.»;

“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ” бүлегендә:

“Министр” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Министр – Абдулганиев Фарид Султанович»;

“Электрон адрес” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Farid.Abdulganiev@tatar.ru»;

“Документация белән эш бүлеге мөдире Ханнанова Гульнара Расилевна» графасын графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Документларның үтәлешен контрольдә тоту бүлеге мөдире Ханнанова Гульнара Расилевна»;

№5 Кушымтада:

«1 көн” сүзләрен “1 эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

«3 көн” сүзләрен “3 эш көне” сүзләре белән алмаштырырга;

“Җир кишәрлеген сайлау акты” сүзләрен төшереп калдырырга

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту өчен министрның беренче урынбасары Р.И.Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Абдулганиев